ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 6 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында сәнәгать сәясәте турында» 2016 елның 21 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $11^1$ пункт өстәргә:
«$11^1$) махсус инвестиция контракты төзү максатларында сәнәгать продукциясе җитештерү урынын килештерү тәртибен раслый;»;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11 статья. **Махсус инвестиция контракты**

1. Татарстан Республикасы территориясендә сәнәгать продукциясен җитештерүне булдыруны йә модернизацияләүне һәм (яисә) үзләштерүне күздә тота торган махсус инвестиция контракты Федераль законның 16 статьясы нигезендә төзелә.
2. Федераль законның $18^1$ статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән технологияне гамәлгә кертү яисә эшләү һәм гамәлгә кертү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыруны күздә токан махсус инвестиция контракты Татарстан Республикасы территориясендә күрсәтелгән технология нигезендә сәнәгать продукциясен серияле җитештерүне үзләштерү максатларында Федераль законның $2^1$ бүлегенә туры китереп төзелә.

3. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус инвестиция контрактын төзегәндә Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы эш йөртә.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән махсус инвестиция контрактын төзегәндә Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы Рәисе эш йөртә.

5. Махсус инвестиция контрактының эчтәлеге Федераль закон нигезендә билгеләнә.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән һәм Татарстан Республикасы тарафыннан Россия Федерациясе катнашыннан башка төзелә торган махсус инвестиция контрактын төзү тәртибе, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән махсус инвестиция контрактын төзү тәртибен һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган типлаштырылган рәвешләрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

7. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән махсус инвестиция контрактын төзү датасыннан соң үз көченә кергән норматив хокукый актлар, Федераль законның 16 статьясындагы 5 өлешендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып, тиешле махсус инвестиция контрактының бер ягы булган инвесторга һәм (яисә) махсус инвестиция контрактында күрсәтелгән башка затларга карата кулланыла.

8. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән махсус инвестиция контрактын төзү датасыннан һәм аның гамәлдә булу вакыты дәвамында инвесторга карата махсус инвестиция контрактын төзү датасыннан соң үз көченә кергән һәм махсус инвестиция контрактын үтәү максатларында инвестор тарафыннан сатып алынган яисә гамәлгә ашырыла торган хокукларны гамәлгә ашыруга чикләүләр һәм (яисә) тыюлар кертә торган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары кулланылмый, әгәр инвестор катнашында тиешле мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларның нигезләмәләрен инвесторга карата куллануның махсус тәртибе алар үзгәргән очракта махсус инвестиция контрактын төзү датасына Татарстан Республикасы законнары белән каралган булса.

9. Әлеге статьяның 8 өлешендәге нигезләмәләре Федераль законның $18^4$ статьясындагы 5 өлешендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла.»;

3) 15 статьяга түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8) Федераль законның $10^1$ статьясында каралган эксперт бәяләмәсен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясының 3 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2024 елның 23 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                                    Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 14 июнь
№ 39-ТРЗ